**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7122**
**29.11.2018**

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ санлы Федераль законның 1 бүлегенең 3 пункты, 8, 9, 11, 11.1 бүлекләре, Россия Казначылыгының «Россия Федерациясе субъектларының (җирле хакимиятләрнең) башкарма хакимият органнары (вазыйфаи затлары) булып саналган дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруга гомуми таләпләрне раслау турында» 2018 елның 12 мартындагы 14н санлы Приказы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентын кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2018 елның 29 ноябрендәге
7122 нче карарына
кушымта

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан
муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу
өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның
административ регламенты

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламенты (алга таба – административ регламент, сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге) сатып алулар өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгели, аерым алганда:

1) контроль субъектларын тикшерү нигезләре, оештыру тәртибе, предметы, формасы, сроклары, кабатлануы һәм андый тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү;

2) контроль органнары күрсәтмәләрен җибәрү, үтәү, гамәлдән чыгаруның тәртибе, сроклары;

3) тикшерүләр үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге, аларның хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы;

4) контроль субъектлары тарафыннан контроль органнары күрсәтмәләре үтәлмәгәндә, шулай ук контроль субъектларының административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре булган эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат алынганда, контроль органнарының, аларның вазыйфаи затларының эш итү тәртибе;

5) контрольне гамәлгә ашырганда бердәм мәгълүмат системасыннан файдалану, шулай ук бердәм мәгълүмат системасында документ әйләнешен алып бару тәртибе.

2. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге законлылык, объективлык, нәтиҗәлелек, бәйсезлек, һөнәри компетентлылык, нәтиҗәләрнең дөреслеге һәм ачыклык принципларына нигезләнә.

3. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыручы эчке муниципаль финанс контроле органы булып Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының финанс идарәсе санала.

4. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының финанс

идарәсенең түбәндәге муниципаль хезмәткәрләре (алга таба – контроль органының вазыйфаи затлары, контроль органы) тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары);

2) финанс идарәсе башлыгы урынбасары;

3) финанс идарәсе башлыгы урынбасары, бюджет бүлеге башлыгы;

4) финанс идарәсенең бюджет сәясәте бүлеге башлыгы;

5) финанс идарәсе бюджет сәясәте бүлегенең баш белгечләре.

5. 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсенең 27 бүлеге нигезендә контроль органы вазыйфаи заты түбәндәге хокукларга ия:

1) нигезле запрос нигезендә контроль чаралар үткәрү өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны язма рәвештә соратып алу;

2) контроль чараларны гамәлгә ашырганда, хезмәт таныклыгын һәм Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турында боерыгы күчермәсен күрсәтеп, контроль субъекты биналарына һәм территорияләренә тоткарлыксыз керү, кайтарылган товарларны, башкарылган эшләрне, күрсәтелгән хезмәтләрнең нәтиҗәләрен күрсәтүне таләп итү, шулай ук контроль буенча кирәкле экспертизалар һәм башка чаралар үткәрү;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозуларны бетерү турында үтәү мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү;

4) сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм башка норматив хокукый актларны бозулар белән бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү, андый административ хокук бозулар турындагы эшләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләгән тәртиптә карап тикшерү, һәм аларны булдырмау буенча чаралар күрү;

5) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы нигезендә, гамәлгә ашырылган сатып алуларны гамәлдән чыккан дип тану турында дәгъва белән судка, арбитраж судына мөрәҗәгать итү.

6. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашырганда контроль органы вазыйфаи затының бурычлары:

1) норматив хокукый акт таләпләрен үтәү;

2) контроль чараларны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турында боерыгы нигезендә үткәрү;

3) контроль субъекты җитәкчесен яки аның вәкаләтле вазыйфаи затын Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чаралар билгеләү турында, күчмә яки камераль тикшерүләр үткәрүне туктату, яңарту, срогын озайту турында, тикшерү төркеменең составы үзгәрү турында боерыгы күчермәсе, шулай ук күчмә яки камераль тикшерүләрнең нәтиҗәләре белән таныштыру;

4) контроль субъекты җитәкчесенә яки аның вәкаләтле вазыйфаи затына (алга таба – контроль субъекты вәкиле) тапшыру яки почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе булган заказлы хат яки адресатның аны алу датасын дәлилләгән башка ысул белән, шул исәптән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, документлар һәм мәгълүматлар, тикшерү актлары, күрсәтмәләр бирү турында запрослар җибәрү;

5) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының камераль яки күчмә тикшерүләр үткәрүнең срогын озайту, камераль яки күчмә тикшерүләр үткәрүне туктату, яңарту турында тиешле боерык чыгарылган көннән башлап 3 эш көненнән артмаган срокта боерык күчермәсен контроль субъектына җибәрү (тапшыру);

6) контроль субъектының запросны алу датасыннан исәпләнә торган запросында контроль субъектының документлар һәм мәгълүматлар тапшыру срогын билгеләү ;

7) җинаять составы билгеләре булган эш итү (эш итмәү) фактлары ачыкланганда, андый факт турындагы мәгълүматны һәм (яки) документларны һәм андый фактны раслый торган башка материалларны, административ регламентның 10 пунктында каралган тәртиптә, хокук саклау органнарына җибәрү;

8) башка дәүләт (муниципаль) органы (вазыйфаи затлары) компетенциясенә караган кимчелек билгеләре турында раслаучы хәлләр яки фактлар ачыкланганда, андый хәлләр һәм фактлар турындагы мәгълүматны, административ регламентның 11 пунктында каралган тәртиптә, тиешле органга (вазыйфаи затка) җибәрү;

9) планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү турында, аларның нәтиҗәләре һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматны 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсенең 24 бүлегендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 27 октябрендәге 1148 нче карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1148 нче карары) белән расланган шикаятьләр, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрын алып бару тәртибендә билгеләнгән срокларда бердәм мәгълүмат системасында һәм (яки) шикаятьләр, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар  һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрында урнаштыру;

10) контроль субъекты тарафыннан кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру;

11) контроль органы вазыйфаи затының нигезле запросы буенча, контроль субъекты тарафыннан мәгълүматлар һәм документлар тапшырылмаган яки үз вакытында тапшырылмаган яисә дөрес булмаган мәгълүмат һәм документлар тапшырылган, контроль субъекты тарафыннан закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә үтәлмәгән очракларда, Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы законнары нигезендә җаваплылык чаралары күрү.

7. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Тикшерүләр күчмә һәм камераль, шулай ук күчмә һәм (яки) камераль тикшерләр кысаларында үткәрелә торган каршы тикшерүләргә бүленә (алга таба – контроль чаралар).

8. Сатып алулар өлкәсендә контроль эшчәнлеге түбәндәгеләргә карата гамәлгә ашырыла (сатып алулар өлкәсендә контроль предметы):

1) 44-ФЗ санлы Законның 18 маддәсендә каралган сатып алулар нигезлелегенә һәм сатып алуның нигезләнгән булуына таләпләрне үтәү;

2) 44-ФЗ санлы Законның 19 маддәсендә каралган сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру кагыйдәләрен үтәү;

3) бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелгән һәм план-графикка кертелгән контракт бәясен, контрактның башлангыч (максималь) бәясен нигезләү;

4) тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) тарафыннан контракт шартлары бозылган очракта, заказчы тарафыннан җаваплылык чаралары күрү һәм башка гамәлләр кылу;

5) кайтарылган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килүе;

6) кайтарылган товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яки күрсәтелгән хезмәтнең исәпкә алу документларында үз вакытында, тулысынча һәм дөрес чагылышы;

7) кайтарылган товардан, башкарылган эштән (аның нәтиҗәсеннән) яки күрсәтелгән хезмәттән файдалануның сатып алуны гамәлгә ашыру максатларына туры килүе.

9. Контроль органның вазыйфаи затлары тарафыннан контроль эшчәнлеген үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән тәртиптә түбәндәге документлар төзелә:

1) тикшерү акты;

2) кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә (кимчелек факты ачыкланган очракта);

3) административ хокук бозу турында беркетмә (административ хокук бозу факты ачыкланган очракта).

10. Җинаять составы билгеләре булган эш итү (эш итмәү) фактлары ачыкланганда, контроль органның вазыйфаи заты, андый факт турындагы мәгълүматны һәм (яки) документларны һәм андый фактны раслый торган башка материалларны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы нигезендә, андый факт ачыкланган көннән башлап 3 эш көне эчендә хокук саклау органнарына җибәрә.

11. Башка дәүләт (муниципаль) органы (вазыйфаи затлары) компетенциясенә караган кимчелек билгеләре турында раслаучы хәлләр яки фактлар ачыкланганда, контроль органның вазыйфаи заты андый хәлләр һәм фактлар турындагы мәгълүматны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы нигезендә, андый хәлләр һәм фактлар ачыкланган көннән башлап 10 эш көне эчендә тиешле органга (вазыйфаи затка) җибәрә.

12. Контроль органы вазыйфаи затлары тарафыннан контроль чаралар кысаларында төзелгән барлык документлар контроль чара материалларына теркәлә, исәпкә алына һәм саклана, шул исәптән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын кулланып.

13. 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсендәге 11 бүлекнең 5 пунктында каралган контроль эшчәнлеген гамәлгә ашырганда сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасыннан файдалану, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында документ әйләнешен алып бару, Россия Казначылыгының 2015 елның 30 декабрендәге 26н санлы Приказы һәм РФ Хөкүмәтенең 1148 нче карары белән расланган Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасыннан файдалану Тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыру өчен мәҗбүри документлар булып күчмә һәм камераль тикшерү нәтиҗәләре турында административ регламентның 51 пункты нигезендә төзелгән хисап, административ регламентның 51 пунктының 1 пунктчасы нигезендә контроль субъектына бирелгән күрсәтмә тора.

14. Контроль органының вазыйфаи затлары контроль чараларны гамәлгә ашыру процессында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

15. Сатып алу өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

1) Башкарма комитет урнашкан Татарстан Республикасы, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 376 кабинет адресы буенча Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының шәхси кабул итүе кысаларында, турыдан-туры;

Башкарма комитетның эш графигы:

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе – җомга | 8.00 – 17.00 |
| Төшке ял | 12.00 – 13.00 |
| Шимбә, якшәмбе | Ял көне |

2) телефон элемтәсе чараларын кулланып, белешмә телефоны буенча: 8 (8552) 30-55-44;

3) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://www.nabchelny.ru (алга таба – шәһәрнең рәсми сайты);

4) мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен: Nche.fbp@tatar.ru электрон почтасы аша;

5) Татарстан Республикасы, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 376 кабинет адресы буенча почта аша хат җибәреп.

16. Административ регламентның 15 пунктында бәян ителгән мәгълүмат контроль орган урнашкан урындагы стендларда һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла.

17. Контроль чараларны гамәлгә ашыру процедураларына түбәндәгеләр керә:

1) контроль чараны билгеләү;

2) контроль чараны үткәрү;

3) контроль чараны үткәрү нәтиҗәләрен гамәлгә ашыру.

18. Контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы административ регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

## 2 бүлек. Контроль чараны билгеләү тәртибе

19. Планлы тикшерү үткәрүне башлау өчен нигез булып, контроль органы контроль чараларының расланган планы нигезендә кабул ителгән, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара билгеләү турындагы боерыгы тора.

20. Чираттагы елга тикшерүләр планына кертү өчен контроль субъектын сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

1) шундый тикшерү үткәрелгән моменттан соң бер ел узу, шундый тикшерү дигәндә, контроль органы тарафыннан карап тикшерү планлаштырылган аналогик мәсьәләләр буенча контроль субъекты эшчәнлегенә карата үткәрелгән (үткәрү планлаштырылган) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнарының контроль чарасы аңлашыла;

2) сатып алулар өлкәсендә гамәлдәге законнарны бозу билгеләре булу турында дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарыннан, бюджет кеременең баш администраторларыннан, бюджет средстволары белән төп эш итүчеләрдән кергән, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларын анализлау нәтиҗәләре буенча ачыкланган мәгълүмат.

21. Бер контроль субъектына карата планлы тикшерүләр үткәрүнең кабатлануы елга 1 тапкырдан артык булырга тиеш түгел.

Контроль субъекты тикшерелә торган чор – агымдагы чор (ай, квартал, ел) һәм (яки) агымдагы елдан алдагы ел.

22. Контроль органының вазыйфаи заты агымдагы елның 1 декабренә кадәр административ регламентка 2 нче кушымтада каралган форма буенча чираттагы елга контроль чаралар планын әзерли һәм аны раслау өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына җибәрә.

23. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары чираттагы елга контроль чаралар планын карап тикшерә һәм аны агымдагы елның 25 декабренә кадәр раслый.

24. Контроль чараларның еллык планына үзгәрешләр кертү, чираттагы елга тикшерүләр планын раслаган тәртиптә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы белән гамәлгә ашырыла, түбәндәге очракларда:

1) контроль субъектын ликвидацияләү, үзгәртеп оештыру;

2) каршы тора алмаслык хәлләр килеп чыгу.

25. Контроль органы чираттагы елга контроль чаралар планы расланган моменттан башлап өч эш көне эчендә, аны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыра.

26. Планнан тыш тикшерүләр Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы нигезендә түбәндәге нигезләрдә үткәрелә:

1) сатып алуда катнашучыдан яисә җәмәгать берләшмәсенең яки юридик затлар берләшмәсенең җәмәгать контролен гамәлгә ашыручылардан контроль субъектының эш итүенә (эш итмәвенә) шикаятьле мөрәҗәгать алыну;

2) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый (хокукый) актларны бозу турында мәгълүмат керү;

3) 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсендәге 22 бүлекнең 2 пункты, 27 бүлекнең 3 пункты нигезендә элек бирелгән күрсәтмәне үтәү срогы чыккан очракта;

4) административ регламентның 51 пунктының 3 пунктчасында каралган очракта.

27. Контроль органының вазыйфаи заты планлы контроль чара үткәрү көненә кадәр биш эш көненнән дә соңга калмый яисә планнан тыш контроль чара үткәрү көненә кадәр ике эш көне алдан Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарына имзалау өчен түбәндәгеләрне җибәрә:

1) административ регламентка 3 нче кушымтада каралган форма буенча планлы контроль чара билгеләү турында боерык проекты;

2) административ регламентка 4 нче кушымтада каралган форма буенча тикшерү үткәрү турында белдерү кәгазе проекты.

28. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары планлы контроль чара билгеләү турында боерык, контроль чара үткәрү турында белдерү кәгазе проектларын бер эш көне эчендә имзалый.

29. Контроль органының вазыйфаи заты Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан планлы контроль чара билгеләү турында боерык, контроль чара үткәрү турында белдерү кәгазе проектларын имзаланган көнне теркәү журналына теркәп куя.

Контроль органының вазыйфаи заты теркәлгән контроль чара билгеләү турында боерыкны, контроль чара үткәрү турында белдерү кәгазен планлы тикшерү үткәрү көненә кадәр 3 эш көне алдан яисә планнан тыш тикшерү үткәрү көненә кадәр 24 сәгать алдан контроль субъектына җибәрә.

## 3 бүлек. Контроль чаралар үткәрү тәртибе

30. Камераль тикшерү контроль органның бер вазыйфаи заты яки контроль органның тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Күчмә тикшерү контроль органның ике вазыйфаи затыннан да ким булмаган составтагы тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелә.

Контроль органның тикшерү төркеме җитәкчесе итеп контроль органның административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи заты билгеләнә.

Камераль тикшерү контроль органының бер вазыйфаи заты тарафыннан үткәрелгән очракта, контроль органның әлеге вазыйфаи заты административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле булырга тиеш.

Контроль чара үткәрүгә вәкаләтләнгән контроль органның тикшерү төркеме вазыйфаи затларының составы үзгәрү, шулай ук контроль органның вазыйфаи затын алмаштыру (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы белән рәсмиләштерелә.

31. Камераль тикшерү контроль орган урнашкан урында, контроль органының запросы буенча контроль субъекты тарафыннан бирелгән документлар һәм мәгълүмат, шулай ук сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы мәгълүматларын анализлау нәтиҗәсендә алынган документлар һәм мәгълүматлар нигезендә үткәрелә.

32. Камераль тикшерүне үткәрү срогы контроль органның запросы буенча контроль субъекты тарафыннан тапшырылган документларны һәм мәгълүматларны алган көннән башлап 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

33. Камераль тикшерү контроль органының бер вазыйфаи заты (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органының тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелгәндә, контроль органның запросы буенча контроль субъекты тарафыннан тапшырылган документларның һәм мәгълүматның тулылыгы, контроль субъектыннан шундый документларны һәм мәгълүматны алган көннән башлап 3 эш көне эчендә тикшерелә.

34. Контроль субъекты тарафыннан тапшырылган документлар һәм мәгълүматның тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре буенча, административ регламентның 33 пункты нигезендә, контроль субъектының соралган документлар һәм мәгълүматны тулы күләмдә тапшырмавы билгеле булган очракта, административ регламентның 38 пункты 4 пунктчасы нигезендә, контроль субъекты тарафыннан тапшырылган документларның һәм мәгълүматның тулылыгын тикшерү тәмамланган көннән соң, камераль тикшерүне үткәрү туктатыла.

Административ регламентның 41 пункты нигезендә, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының камераль тикшерү үткәрүне туктату турында боерыгының күчермәсен җибәрү белән бер үк вакытта тикшерү үткәрү өчен кирәкле, җитмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыру турында запрос та кабат җибәрелә.

Контроль органның кабат җибәрелгән запросы буенча контроль субъекты тарафыннан документлар һәм мәгълүмат тапшырылмаган очракта, административ регламентның 38 пункты 4 пунктчасы нигезендә тикшерүне туктату срогы узгач, тикшерү яңартыла.

Контроль субъекты тарафыннан документлар һәм мәгълүмат тапшырылмау факты тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелә торган актта язылып куела.

35. Күчмә тикшерү контроль субъектының урнашкан урыны яки фактик эшчәнлек алып барган урыны буенча үткәрелә.

36. Күчмә тикшерү үткәрү срогы 30 эш көненнән дә артып китәргә тиеш түгел.

37. Күчмә тикшерү үткәрү барышында контроль субъектының документтагы һәм фактик эшчәнлеген өйрәнү буенча контроль гамәлләр башкарыла.

Документларны өйрәнү буенча контроль гамәлләр финанс, бухгалтерлык, хисап документларын, сатып алуларны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру турында документларны һәм контроль субъектының, материаль җаваплы вазыйфаи затларының телдән һәм язмача аңлатмаларын исәпкә алып, башка документларын анализлау һәм контроль буенча башка гамәлләрне тормышка ашыру юлы белән үткәрелә.

Фактик эшчәнлекне өйрәнү буенча контроль гамәлләр карау, инвентаризацияләү, күзәтү, яңадан исәпләү, экспертиза, контроль үлчәүләр һәм контроль буенча башка гамәлләрне тормышка ашыру юлы белән үткәрелә.

38. Контроль органы вазыйфаи затының (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органның тикшерү төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан кабул ителгән боерык буенча күчмә яки камераль тикшерүне үткәрү, түбәндәге очракларда гомуми срогы 30 эш көненнән артмаган срокка туктатыла:

1) каршы тикшерү үткәргән чорга, ләкин 20 эш көненнән дә артык түгел;

2) экспертизалар оештыру һәм үткәрү чорына, ләкин 20 эш көненнән дә артык түгел;

3) контроль чара үткәрүгә тоткарлык һәм (яки) контроль чара үткәрүдән читләшү чорына, ләкин 20 эш көненнән дә артык түгел;

4) административ регламентның 34 пункты нигезендә контроль органының кабаттан җибәрелгән запросы буенча контроль субъекты тарафыннан документлар һәм мәгълүмат тапшыру өчен кирәкле чорга, ләкин 10 эш көненнән дә артык түгел;

5) контроль органының вазыйфаи затына (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органының тикшерү төркеменә бәйсез сәбәпләр буенча, алга таба контроль чаралар үткәрү мөмкин булмаган хәлләр булганда, каршы тора алмаслык хәлләр килеп чыгуны да кертеп, 20 эш көненнән артмаган чорга.

39. Күчмә һәм камераль тикшерү үткәрүне яңарту турында боерык Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан 2 эш көненнән артмаган срокта кабул ителә:

1) административ регламентның 38 пунктының 1, 2 пунктчалары нигезендә каршы тикшерү һәм (яки) экспертиза үткәрү тәмамланганнан соң;

2) тикшерү үткәрүне туктатуның административ регламентның 38 пунктының 3-5 пунктчаларында күрсәтелгән сәбәпләре бетерелгәннән соң;

3) тикшерү үткәрүне туктатуның административ регламентның 38 пунктының 3-5 пунктчаларында күрсәтелгән срогы чыкканнан соң.

40. Күчмә һәм камераль тикшерү үткәрү срогы Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы буенча 10 эш көненнән дә артмаган срокка озайтылырга мөмкин.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының контроль чара срогын озайту турында боерыгы контроль органы вазыйфаи затының (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органның тикшерү төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате нигезендә кабул ителә.

Контроль чараның срогын озайту өчен нигез булып, тикшерү үткәрү барышында контроль субъекты эшчәнлегендә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый (хокукый) актлар бозылу турында, өстәмә өйрәнүне таләп итече мәгълүмат алыну тора.

41. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының күчмә яки камераль тикшерүне үткәрү срогын озайту, күчмә яки камераль тикшерү үткәрүне туктату, яңарту турында боерыклары административ регламентка 5 нче кушымтада каралган форма буенча рәсмиләштерелә, анда тикшерүне үткәрү срогын озайту, тикшерү үткәрүне туктату, яңарту нигезләре күрсәтелә.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының күчмә яки камераль тикшерүне үткәрү срогын озайту, күчмә яки камераль тикшерү үткәрүне туктату, яңарту турында боерыгы күчермәсе, тиешле боерык чыгарылганнан соң 3 эш көненнән дә артмаган срокта, контроль субъектына җибәрелә (тапшырыла).

42. Күчмә һәм камераль тикшерү кысаларында, контроль органы вазыйфаи затының (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органның тикшерү төркеме җитәкчесенең нигезле мөрәҗәгате нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан кабул ителгән боерык буенча каршы тикшерү оештырыла.

Каршы тикшерү үткәргәндә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарын һәм аның нигездә кабул ителгән норматив хокукый (хокукый) актларны бозу фактларын билгеләү һәм (яки) раслау яисә кире кагу максатларында контроль гамәлләр үткәрелә.

43. Каршы тикшерү, административ регламентның 30, 35, 37 пунктлары нигезендә күчмә һәм камераль тикшерүләр өчен билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

Каршы тикшерүнең срогы 20 эш көненнән артырга тиеш түгел.

44. Контроль органының запросы буенча документлар һәм мәгълүмат тапшырылмаган яки үз вакытында тапшырылмаган яисә дөрес булмаган документлар һәм мәгълүмат тапшырылган очракта, контроль органы

тарафыннан Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы законнары нигезендә җаваплылык чаралары кулланыла.

## 4 бүлек. Контроль чараларның нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм гамәлгә ашыру

45. Каршы тикшерү нәтиҗәләре контроль органының вазыйфаи заты (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органы тикшерү төркеменең барлык әгъзалары (тикшерү тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелгәндә) тарафыннан тикшерү үткәрүнең соңгы көнендә акт белән рәсмиләштерелә һәм күчмә яки камераль тикшерү материалларына тиешенчә теркәлә.

Каршы тикшерү нәтиҗәләре буенча контроль субъектына күрсәтмәләр бирелми.

46. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча, контроль чара үткәрү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән башлап исәпләгәндә 3 эш көненнән артмаган срокта, административ регламентка 6 нчы кушымтада каралган форма буенча, контроль органының вазыйфаи заты (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органы тикшерү төркеменең барлык әгъзалары (тикшерү тикшерү төркеме тарафыннан үткәрелгәндә) тарафыннан имзалана торган акт рәсмиләштерелә.

47. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка экспертизалар нәтиҗәләре, фото-, видео- һәм аудиоматериаллар, каршы тикшерү акты (ул үткәрелгән очракта), шулай ук контроль чаралар үткәрү барышында алынган башка материаллар теркәлә.

48. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт, ул имзаланган көннән башлап 3 эш көненнән дә артмаган срокта, контроль субъекты вәкиленә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш.

49. Контроль субъекты күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актка язма рәвештәге каршылыгын, андый актны алган көннән башлап 10 эш көненнән дә артмаган срокта бирү хокукына ия.

Контроль субъектының язма рәвештәге каршылыгы тикшерү материалларына теркәлә.

50. Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән акт, контроль субъектының каршылыклары (алар булган очракта) һәм күчмә яки камераль тикшерүнең башка материаллары Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан карап тикшерелергә тиеш.

51. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән актны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, контроль субъектының каршылыкларын (алар булганда) һәм күчмә яки камераль тикшерүнең башка материалларын исәпкә алып, акт имзаланган көннән башлап 30 эш көне эчендә түбәндәгеләр турында боерык чыгара:

1) 44-ФЗ-санлы Законда билгеләнгән очракларда, үтәү мәҗбүри булган күрсәтмә бирү турында;

2) күрсәтмә бирү өчен нигезләр булмау турында;

3) планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында.

52. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан, административ регламентның 51 пунктында каралган, югарыда күрсәтелгән боерык имзалану белән бер үк вакытта, тикшерү үткәргәндә ачыкланган һәм контроль субъектының каршылыкларын (алар булганда) карап тикшергәннән соң расланган һәм актта чагылдырылган барлык кимчелекләрне дә үз эченә алган күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турында хисап та раслана.

Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турындагы хисап тикшерүне үткәргән контроль органының вазыйфаи заты (камераль тикшерү бер вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелгәндә) яисә контроль органның тикшерү төркеме җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Күчмә яки камераль тикшерү нәтиҗәләре турындагы хисап тикшерү материалларына теркәлә.

53. Контроль субъекты вәкиленә күрсәтмә, административ регламентның 51 пункты 1 пунктчасы нигезендә үтәлү мәҗбүри булган күрсәтмә бирелгән көннән башлап 5 эш көненнән артмаган срокта җибәрелә (тапшырыла).


54. Күрсәтмә административ регламентка 7 нче кушымтада каралган форма буенча рәсмиләштерелә һәм аны үтәү сроклары күрсәтелергә тиеш.

55. Контроль органы күрсәтмәсен билгеләнгән срокта үтәмәгән очракта, әлеге күрсәтмәне үтәмәгән затка карата Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык чаралары кулланыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
1 нче кушымта

# САТЫП АЛУЛАР ӨЛКӘСЕНДӘ КОНТРОЛЬНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ БЛОК-СХЕМАСЫ



Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
2 нче кушымта

Башкарма комитет Җитәкчесе
урынбасары, финанс идарәсе
башлыгы тарафыннан
Расланган:

_________ _______________________

(имза, имза расшифровкасы - ф.и.а.и.)
«_____» ________________ 20___ ел

________елга сатып алулар өлкәсендә контроль буенча контроль чаралар үткәрү планы

| Контроль субъектының исеме | Салым түләүченең идентификация номеры | Тикшерү үткәрүнең максаты | Тикшерү үткәрү өчен нигез | | Тикшерү үткәрүнең башлану датасы | Планлы тикшерүне үткәрү срогы (эш көннәре) | Тикшерү үткәрү формасы (камераль яки күчмә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Соңгы тикшерү тәмамланган дата | Юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлаган дата | | | |
| | | | | | | | |

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
3 нче кушымта

Контроль чара билгеләү турында боерык формасы[1]

___________________________________
____________________________ карата
(контроль субъектының исеме)
___________________________________
(тикшерүнең төрен күрсәтергә: планлы /плансыз
күчмә/камераль тикшерүләр, каршы тикшерү)
үткәрү турында
_________________________________________________________________ нигезендә
(тикшерү үткәрүнең хокукый нигезлелеген күрсәтергә)

1. Сатып алулар өлкәсендә контроль кысаларында ________________________
(контроль субъектының исеме)
____________________________________________ карата тикшерү үткәрергә.
(тикшерү төрен, формасын күрсәтергә2)

2. Контроль субъектының урнашкан урыны ______________________.
3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле затлар итеп билгеләргә:
1) _______________________________________________________________;
2) _______________________________________________________________.
4. Тикшерү үткәрүгә экспертлар, эксперт оешма вәкилләре сыйфатында түбәндәге затларны җәлеп итәргә:
________________________________________________________________
(Ф.И.А.и. күрсәтергә)

5. Билгеләргә:
1) әлеге тикшерү түбәндәге максатта үткәрелүне:
__________________________________________________________________;
2) түбәндәгеләрне карау әлеге тикшерүнең бурычы булып тора:
- _________________________________________________________________;
- _________________________________________________________________.

---

[1] Контроль чара билгеләү турындагы боерык Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары бланкында рәсмиләштерелә;
[2] Каршы тикшерү үткәргәндә нинди тикшерү кысаларында (планлы/планнан тыш күчмә/камераль) үткәрелүен күрсәтергә

6. Әлеге тикшерүнең предметы булып түбәндәгеләр тора:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

7. Тикшерүне үткәрү срогы:

«____» __________ 20___елдан «____» __________ 20___елга кадәр

8. Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен контроль субъекты тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге:

1) ________________________________________________________;

2) ________________________________________________________;

3) ________________________________________________________;

4) ________________________________________________________.

Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары,
финанс идарәсе башлыгы Имза Имза расшифровкасы

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
4 нче кушымта

Контроль чара үткәрү турында белдерү кәгазе формасы[3]

________________________________________
________________________________________
________________________________________
________________________________________
(контроль субъектының адресы, Ф.И.А.и. – физик зат өчен, контроль субъектының исеме – юридик зат өчен)

Хөрмәтле_________________!

Моның белән Сезгә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгының «___» _______ 20___елның № ____ боерыгы нигезендә «____» __________ 20___елдан «____» __________ 20___елга кадәр ________________________________________________________ карата
(контроль субъектының исемен/Ф.И.А.и. күрсәтергә)

________________________________ тикшерү үткәрелү турында белдерәбез,
(тикшерүнең төрен, формасын күрсәтергә)

аның предметы: _____________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы | Имза | Имза расшифровкасы |

[3] Белдерү кәгазе Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары бланкында рәсмиләштерелә

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
5 нче кушымта

Тикшерү үткәрү срогын туктату (яңарту, озайту) турында боерык формасы [4]

________________________________________
(тикшерү төрен күрсәтергә: планлы /планнан тыш күчмә/камераль тикшерүләр, каршы тикшерү)
тикшерүне үткәрү срогын туктату (яңарту, озайту) турында

________________________________________________________________нигезендә
(тикшерү үткәрүнең хокукый нигезлелеген күрсәтергә)

1. ______________________________________________________________________
(контроль субъектының исеме)
Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының «____» _____________ 20___ елның № _______ боерыгы белән «____» _______________ 20___ елга кадәр (елдан соң) башланган _________________________________________________________________
(тикшерү төрен, формасын күрсәтергә)

тикшерү үткәрүнең срогын туктатып торырга (яңартырга, озайтырга).

2. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән тикшерү үткәрү срогын туктату (яңарту, озайту) турында ______________________________________________
(контроль субъектының исемен/Ф.И.А.и. күрсәтергә)

белдерергә.

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитет<br>Җитәкчесе урынбасары,<br>финанс идарәсе башлыгы | Имза | Имза расшифровкасы |

[4] Боерык Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары бланкында рәсмиләштерелә

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
6 нчы кушымта

Тикшерү акты формасы

ТИКШЕРҮ АКТЫ[5]

«____» __________ 20___ел                                                  № ____________

______________________________________________________________нигезендә
(Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы реквизитларын күрсәтергә)

«____» _________ 20___елдан «____» _________ 20___елга кадәр _____ эш көне эчендә ________________________________________________ карата
(Ф.И.А.и., контроль субъектының исеме)

_____________________________________________ тикшерүләр үткәрелде.
(тикшерүнең төрен күрсәтергә: планлы/планнан тыш күчмә/камераль тикшерүләр)

Башкарма комитетның тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары:

1) ____________________________________________________________;
(Башкарма комитет вазыйфаи затының вазыйфасын, Ф.И.А и.күрсәтергә)

2) ____________________________________________________________.
(Башкарма комитет вазыйфаи затының вазыйфасын, Ф.И.А и.күрсәтергә)

Тикшерү үткәрү барышында дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланды/ачыкланмады:

______________________________________________________________
______________________________________________________________
______________________________________________________________
___________________________________________________

Актка теркәлгән документлар:

1) ____________________________________________________________;
2) ____________________________________________________________;
3) ____________________________________________________________;
4) ____________________________________________________________.

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның тикшерү үткәргән вазыйфаи зат(лар)ының вазыйфасы | Имза | Имза расшифровкасы |

---

[5] Тикшерү акты Башкарма комитетның финанс идарәсе бланкында рәсмиләштерелә

Тикшерү үткәрү турындагы боерык белән таныштырылды

«____» __________ 20___ел Имза Имза расшифровкасы

(контроль субъекты җитәкчесе яисә аның вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалана)

________________________________________________________________________

(контроль субъекты җитәкчесенең яисә аның вәкаләтле вәкиленең Ф.И.А.и.)

________________________________________________________________________

тикшерү акты белән танышудан баш тартты[6].

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның тикшерү үткәргән вазыйфаи зат(лар)ының вазыйфасы | Имза | Имза расшифровкасы |

________________________________________________________________________

(контроль субъекты җитәкчесенең яисә аның вәкаләтле вәкиленең Ф.И.А.и.)

Башкарма комитетның вазыйфаи затына территориягә, биналарга, төзелешләргә, корылмаларга яки бүлмәләргә керүенә тоткарлык тудырган[87].

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның тикшерү үткәргән вазыйфаи зат(лар)ының вазыйфасы | Имза | Имза расшифровкасы |

---

[6] Тикшерү акты белән танышудан баш тарткан очракта, Башкарма комитетның тикшерү үткәргән вазыйфаи заты белән тутырыла һәм имзалана

[7] Башкарма комитетның күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларын территориягә, биналарга, төзелешләргә, корылмаларга яки контроль субъекты бүлмәләренә керүләренә тоткарлык тудырылган очракта

Эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына
7 нче кушымта

Кимчелекләрне бетерү турында күрсәтмә [8]

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарының «____» __________ 20__ елның № ___ боерыгы белән «____» ______________ 20___ ел № ___ тикшерү акты нигезендә __________________________________________ карата үткәрелгән ___________________________________________________ нәтиҗәләре буенча
(тикшерүнең төрен, формасын күрсәтергә)

БИЛГЕЛӘНДЕ:

Россия Федерациясе законнарында һәм дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында башка норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу:

1) ________________________________________________________________ ____________________________________________________________________;

2) ________________________________________________________________ ____________________________________________________________________.

Бәян ителгәннән чыгып,

ТАЛӘП ИТӘМ:

1. _________________________________________________________________

2. _________________________________________________________________

3. _________________________________________________________________

4. Билгеләнгән кимчелекләрне «____» _____ 20___ елга кадәр срокта бетерергә.

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитет<br>Җитәкчесе урынбасары,<br>финанс идарәсе башлыгы | Имза | Имза<br>расшифровкасы |

[8] Күрсәтмә Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары бланкында рәсмиләштерелә